СОВЕТ КАТМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Кирова, д.74, с. Катмыш,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422177

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАТМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Киров ур., 74 нче йорт, Катмыш авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422177

тел.(факс): (85563) 2-72-03; e-mail:Katmish.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение Карар
22 июнь 2022 ел №2-16

Катмыш авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы,«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы»муниципаль берәмлеге Уставы,Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының 2015 елның 15 октябрендәге 4-2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмә, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы,Катмыш авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә, кадрлар эше буенча аерым функцияләрне тапшыру турында төзелгән килешүләр нигезендә,Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районыКатмыш авыл җирлеге Советының 2021 елның 12 ноябрендәге 1-12 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында нигезләмә»не үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районыКатмыш авыл җирлеге Советының 2016 елның 3 мартындагы 1-7 номерлы карары белән расланган«Мамадыш муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләренә аттестация үткәрү турында нигезләмә»не үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында, Мамадыш муниципаль районы http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге башлыгына  йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Катмыш авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе / И.Г.Габидуллин/